# КАРАР

## Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге составына керүче Прости торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 24 октябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 24 октябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Прости авыл җирлеге Прости торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Әлеге сумманың 50% ы күләмендә 2 төркем инвалидлар түли. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Мәктәп урамы буенча автомобиль юлының юл полотносын асфальт белән чокырларны ямау (килешү буенча эшләр өчен түләү),
- мөселман зиратына алып баручы юлга вак таш җәю (китерү килешүе буенча вак таш сатып алу; килешү буенча транспорт хезмәтләре өчен түләү),
- Луговая, Зеленая, Гагарин һәм 2нче Дачная урамнары буенча вак таш җәелгән юлларга вак таш җәю (китерү килешүе буенча вак таш сатып алу; килешү буенча транспорт хезмәтләре өчен түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 517 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 261 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 148 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 113 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге составына керүче Прости торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. «Түбән Кама муниципаль районының Прости авыл җирлеге Прости торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Әлеге сумманың 50% ы күләмендә 2 төркем инвалидлар түли. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Мәктәп урамы буенча автомобиль юлының юл полотносын асфальт белән чокырларны ямау (килешү буенча эшләр өчен түләү),
- мөселман зиратына алып баручы юлга вак таш җәю (китерү килешүе буенча вак таш сатып алу; килешү буенча транспорт хезмәтләре өчен түләү),
- Луговая, Зеленая, Гагарин һәм 2нче Дачная урамнары буенча вак таш җәелгән юлларга вак таш җәю (китерү килешүе буенча вак таш сатып алу; килешү буенча транспорт хезмәтләре өчен түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Прости авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Прости авыл җирлеге башлыгы Д.А. Бәдәртинов